# КЕРЕШ СҮЗ

Татарстан ике зур географик зона – урман һәм дала зоналары чигенә урнашкан. Ике төрле табигый географик зонаны эченә алганлыктан, республикабызның үсемлекләр дөньясы ифрат бай һәм күптөрле. Белгечләр ачыклаганча, безнең урманнарда, кырларда, болын-тугайларда чәчәкле үсемлекләрнең генә дә 1300 дән артык төре үсә икән. Җөмһүриятебезнең төньяк-көнчыгышында *чыршы, ак чыршы, мәче табаны, мүк җиләге, нарат җиләге, кымызлык, мүк үләне* кебек үсемлекләргә бай тайга урманнары җәелеп киткән. Идел елгасының уң ягындагы имәнлек-туйралыкларда борынгы флораның инде сирәк очрый торган вәкилләре сакланып калган. Мисал өчен, үләнчел үсемлекләрдән *солыча, тайтояк, кындырак, башмакчәчәк, мәшкәрә* һ.б.ны санап үтәргә мөмкин. Көньяктагы, бигрәк тә көньяк-көнчыгыштагы ачык урыннарда *типчак, нечкаяк, кылган, ташъяргыч, кәрләч* кебек типик дала үләннәрен очратабыз. Татарстанның күлләргә һәм сазлыкларга бай икәнлеген дә онытмыйк. Бу сулык мәйданнарының шактый өлешен *камыш, җикәнбаш, бака ефәге, кылычүлән* кебек үсемлекләр биләп тора. Болар – фәкать Татарстан җирендә генә булган үсемлекләр. Татарлар яши торган башка өлкәләрдә дә тагын никадәр үзенчәлекле атамалар бар. Кыскасы, үсемлек атамалары телебез лексик байлыгының шактый өлешен тәшкил итә.

Татар телендә үсемлек атамалары (фитонимнар) сүзлекләрен эшләү бөтенләй үк яңа бер өлкә түгел. Алар берникадәр дәрәҗәдә XVIII гасырлардан алып чыга барган сүзлекләрдә (С. Хәлфин, 1783; А. Троянский, 1833; 1835; Л. Будагов, 1869; 1871; В. Радлов, 1893 – 1911; Җ. Вәлиди, 1927, 1929; «Борынгы төрки телләр сүзлеге»ндә, 1969 һ.б.да) чагылыш тапкан. XIX гасыр азагында К. Насыйриның «Гөлзар вә чәмәнзар» («Үләнлек

һәм чәчәклек»), (1894), «Гыйльме зирагать» («Игенчелек белеме эше»), (1892), «Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр»), (1894) кебек терминологик сүзлекләрдә үз җирлегебездәге үсемлек атамалары тагын да камилләштеребрәк бирелгән. Соңгы 15 – 20 елда ботаника белгечләре дә, филолог галимнәр дә бу өлкәгә караган русча-татарча, татарча-русча тәрҗемәле сүзлекләрне, танытычларны төзеп бастырып торды. Терминологик сүзлекләрнең максаты баш сүз итеп алынган русча (яки татарча) терминның татарчага (яки русчага) ничек тәрҗемә ителүен билгеләүдән, төгәл тәңгәлләрен куеп чыгудан гыйбарәт иде. Әлбәттә, чорына күрә бу кадәресе дә канәгатьләндерде, ләкин хәзерге вакытта тәрҗемәле сүзлекләргә генә түгел, тәфсилле һәм системалы аңлатмалы сүзлекләргә дә ихтыяҗ зур. Бүгенге белгечләрне, тәрҗемәчеләрне, фәнни хезмәткәрләрне сүзен сүзгә тәрҗемәләр генә канәгатьләндереп бетерми. Һәр атамага, һәр терминга аерым, күз алдына китерерлек, аңа реаль белешмә бирерлек аңлатма кирәк. Татарның энциклопедик белемгә ия булган галиме Каюм Насыйри үләннәр дөньясына караган «Гөлзар вә чәмәнзар» хезмәтендә «...һәрбер үсемлек вә үлән белән таныштыру өчен алар (истилах сүзләре) зарур нәрсәләр, чөнки таныштыруына карап гомердә күрмәгән үләнне белергә һәм таныргa мөмкин», – дип яза. Галимнең моннан бер гасыр элек әйтелгән сүзләре бүген дә актуаль яңгырый һәм әлеге хезмәтнең зарурлыгын тагын бер кат ассызыклый.

«Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге» – төзелеш принциплары ягыннан беренче тәҗрибә. Сүзлек төрле елларда басылып чыккан, шул өлкәгә караган терминологик һәм аңлатмалы сүзлекләргә таянып эшләнде.

Тәкъдим ителгән Сүзлекнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– кулланышта булган үсемлек атамаларын мөмкин кадәр тулырак туплау;

– термин-атамага мөмкин кадәр төгәл аңлатма бирү;

– сүзләрнең кулланылыш дәрәҗәсен мөмкин кадәр киңрәк ачыклау;

– фәнни терминнар белән бергә халык сөйләшләрендә киң таралыш тапкан җирле атамаларны да күрсәтә бару (җирле кеше, белгеч үзенә электән таныш сүз-атама аша гына объектларны

дөрес күзаллый, шуннан соң гына фәнни атаманы да урынлы куллана ала);

– атамаларның мәгънәсен тулырак һәм төгәлрәк ачу өчен, иллюстратив материал бирү;

– кайбер сүзләрнең фәнни язылышын тәэмин итү;

– табигать фәннәре буенча татар терминологиясен камилләштерү.

Сүзлектә Урта Идел буе, бигрәк тә Татарстан җирендә үсә торган үсемлек атамалары зур урын алып тора.

Татар телендә үсемлекнең төзелешенә, аның өлешләренә караган шактый күп лексик берәмлекләр дә бар. Шуңа да сүзлектә фитонимнар белән бергә анатомиясенә, физиологиясенә караган сүзләр, бер төрдәге үсемлекләр күпләп үскән урын атамаларының да кайберләре урын алды.

Үсемлек атамалары тупланган сүзлекләрдән аермалы буларак, бу хезмәттә халык арасында киң кулланылышта булган гөмбә исемнәре һәм аларның төзелешенә караган терминнар да кертелде.

Фитонимнар һәм алар белән бәйле лексика сигез төркемгә бүленеп каралды. Атамаларның мөмкин булганча татарча вариантларын бирү күздә тотылды. Шуңа күрә телебездәге әлеге катлам лексикасының искергән, кулланылыштан төшеп калган вариантлары да бирелде.

Җирле сөйләшләрдә гаять бай материал тупланганын истә тотып, сүзлектә диалекталь атамаларны һәм фонетик вариантларны да күрсәтүне кирәк дип санадык. Мондый атамаларны кулланылыш даирәсен күрсәтеп терминологик сүзлекләргә туплау термин булмаган сүзләрне ачыкларга, үсемлек атамаларына караган терминосистеманы камилләштерергә ярдәм итәчәк.

Сүзлекне төзүдә татар тел белеменең казанышлары, лексикографиясенең бай традицияләре нигез итеп алынды. Төрки телләрнең, рус һәм башка телләрнең лексикография өлкәсендәге уңай тәҗрибәсе истә тотылды.

Атамаларның кулланыш ешлыгын күрсәтеп, мәгънәләрен тулырак һәм төгәлрәк ачу максаты белән мөмкин булган кадәр күләмдә, нигездә, әдәби әсәрләрдән тупланган, иллюстратив материал тәкъдим ителде.

Шулай ук сүзлектән файдаланучыларга уңайлыклар тудыру, татарча атамаларның эчтәлегенә, шигъриятенә тирәнрәк

төшенергә ярдәм итү өчен, сүзлек ахырында үсемлекләргә бәйләнешле мәкаль-әйтемнәр, сынамыш һәм ышанулар кушымта итеп бирелде.

Татар теленең үзенчәлекле лексик байлыгын туплаган, аңлатмалары иллюстратив мисаллар белән ныгытылган әлеге Сүзлек киң катлам укучылар, биологлар, табигатьне саклаучылар, сүзлекчеләр, тәрҗемәчеләр, радио һәм телевидение, матбугат хезмәткәрләре, укытучылар, шулай ук татар телен өйрәнүчеләр өчен файдалы белешмәлек булачак.

Сүзлеккә карата фикер-тәкъдимнәрегезне, төзәтмәләрне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһәре, К. Маркс ур., 12
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтының лексикография бүлеге
E-mail: iyali.anrt@mail.ru